ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
КАЛМАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

**КАРАР**

“08” ноябрь 2024 ел Калмаш авылы № 3

“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлегенең Калмаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Калмаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлегенең Калмаш авылында 2024 елның 22 ноярендә 18.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләләрне расларга:

“Калмаш авыл җирлегенең Калмаш авылы территориясендә 2025 елда балигъ булган, Калмаш авыл җирлегенең Калмаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 1000 ( мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 500 (биш йөз) сум күләмендә билгеләргә һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә өлешчә мобилизация буенча хәрби хезмәткә чакырылган гражданнарны, аларның гаилә әгъзаларын үзара салым буенча түләүдән азат итәргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Калмаш авылы юлларын ремонтлау (асфальт валчыклары сатып алу);
- урамнарны яктырту (электр материаллары сатып алу, Калмаш авылында урамнарны яктырту челтәрләрен монтажлау һәм урнаштыру);
- су белән тәэмин итү һәм су бүлү системаларын, суэтем башняларын, скважиналарны һәм су белән тәэмин итү чыганакларыннан су алуны, аны чистартуны, транспортировкалауны һәм халыкка су бирүне тәэмин итүче башка инженерлык корылмаларын проектлау, төзү һәм ремонтлау;(Калмаш авылында су торбасын алыштыру)

“ӘЙЕ” “ЮК”.

3. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Калмаш авылы, Центральная урамы, 32 йорты СДК “Яшлек” каршында гражданнар җыенын үткәрергә.
4. Тукай муниципаль районы Калмаш авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре”(https://tukay.tatarstan.ru/) бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында(http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Калмаш авыл җирлеге Башлыгы




Ф.В.Шәвәлиев